МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.10.2020 г.Казань № 764

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 19 октяберендә 6959 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 17 ноябрендәге 628 номерлы боерыгы белән расланган Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләрне кертү турында

Пенсияләре «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» Федераль законнар нигезендә билгеләнгән

пенсионерларга, 60 һәм 55 яшькә җиткән гражданнарга (ир-атлар һәм хатын-кызлар) пенсия билгеләү шартларына туры килүче гражданнарга, 60 һәм 55 яшькә җиткән гражданнарга, пенсия билгеләү шартларына туры килүче гражданнарга, пенсиянең 2018 елның 31 декабренә торышы буенча күрсәтелгән федераль законнарда каралган, әмма 60 һәм 55 яшькә җитмәгән (ир-атлар һәм хатын-кызлар) гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатыннан, б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (07.06.2016 ел № 317, 11.07.2016 ел № 395, 28.11.2016 ел № 668, 08.06.2017 ел № 349, 15.05.2018 ел № 367, 24.09.2018 ел № 897, 21.02.2019 ел № 129, 19.04.2019 ел № 285, 10.09.2019 ел № 688, 14.11.2019 ел № 1007, 05.02.2020 ел № 65, 08.05.2020 ел № 289, 14.07.2020 ел № 515 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) 2014 елның 17 ноябрендәге 628 номерлы «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына китерелгән үзгәрешләрне кертәргә.

Министр Э.А. Зарипова

Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 28 октябрендәге 764 номерлы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының

2014 елның 17 ноябрендәге 628 номерлы «Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган Пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә күрсәтелгән федераль законнар күздә тоткан пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән гражданнарга юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.6 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Документлар ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча кабул ителә:

Россия Федерациясе Пенсия фонды башкара торган пенсионерларның пенсияләре, компенсация түләүләре һәм өстәмә айлык матди тәэмин ителеше турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

мөрәҗәгать итүченең күчемсез мөлкәте барлыгы турында белешмәләр (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән (алга таба - Росреестр);

билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак бина турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарыннан);

мөрәҗәгать итүченең транспорт чараларының, үзйөрешле транспорт чараларының һәм башка төр техниканың булуы турында белешмәләр (вәкаләтле органнардан);

барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан иминиятләштерелгән затның социаль түләүләр күләме турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

эш бирүченең (иминиятләштерүченең) физик заты файдасына исәпләнгән түләүләр һәм башка төр күчерүләр суммасы турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы (алга таба - Россия Эчке эшләр министрлыгы) тарафыннан түләнә торган пенсия күләме турында белешмәләр;

Россия Федерациясе Оборона министрлыгы (алга таба - Россия Оборона министрлыгы) тарафыннан түләнә торган пенсия күләме турында белешмәләр;

медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча, һөнәри эшкә яраклылык югалган булса, медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча, иминиятләштерелгән затның үлеме иминият очрагы килеп туган очракта, житештерүдәге бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча айлык иминият түләүләре турында белешмәләр (Россия Федерациясе Социаль иминият фондыннан);

вакытлыча эшкә яраксызлык буенча пособие турында белешмәләр (Россия Федерациясе Социаль иминият фондыннан);

эшсезлек буенча пособиеләрнең барлык төрләрен түләүләр һәм эшсезләргә башка түләүләр алуы (алмавы) турында белешмәләр (Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт учреждениеләреннән (алга таба - эш белән тәэмин итү үзәкләре));

мөрәҗәгать итүче балигъ булмаган зат булган очракта, законлы вәкилнең вәкаләтләрен раслау өчен тууны дәүләт теркәве турында белешмәләр (вәкаләтле органнардан);

мөрәҗәгать итүче балигъ булмаган зат булган очракта, законлы вәкилнең вәкаләтләрен раслау өчен ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарыннан);

тәрбиягә алучы гаиләгә баланы тапшыру турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарыннан);

опека (попечительлек) билгеләү турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарыннан);

"Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында", "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" һәм "Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында" Федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына гражданның 2018 елның 31 декабренә торышы буенча туры килүе турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

шәхси исәп-хисап счетының иминият саны турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына (вәкаләтле оешмалардан) салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр.

Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша мөрәҗәгать иткәндә, өстәмә рәвештә ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча алына:

мөрәҗәгать итүче паспортының дөреслеген раслау турында белешмәләр (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгыннан);

мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлүенең дөреслеген раслау турында белешмәләр (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгыннан);

Мөрәҗәгать итүче югарыда күрсәтелгән белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы.

Күрсәтелгән документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмаларда, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон формада алынырга һәм әлеге Регламентта, 2.5 бүлектә каралган тәртиптә билгеләнгәнчә тапшырылырга мөмкин.

Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәткәндә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне көйли торган норматив хокукый актларда тапшыру яисә үтәү каралмаган гамәлләрне тормышка ашыру өчен документлар һәм мәгълүмат бирүне;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен түләү кертүне раслаучы документлар һәм мәгълүмат бирүне;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, беренче тапкыр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда документларның һәм мәгълүматның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат тапшыруны»;

2.8 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен шушы Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгат итүе һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычның булуы нигез була.»;

2.14 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналар һәм корылмаларда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (биналарда) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктындагы 1 пунктчасында каралган белешмәләр, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә формалары урнаштырылган мәгълүмати стендлар җиһазландырыла.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтелгән объектлардан (алга таба – объект) файдалану өчен инвалидларга түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү максатларында объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче объектның хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырылган кресло-коляска ярдәмендә;

в) объектка кергәндә транспорт чарасына утыру һәм төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска файдаланып һәм, кирәк булганда, объектның хезмәткәрләре ярдәмендә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре тотрыклы бозык булган инвалидларны объект территориясе буенча озата бару;

д) объектка кергәндә һәм аннан чыкканда инвалидка ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының мөмкин булган маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектка һәм дәүләт хезмәте күрсәтүләргә каршылыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүматны аларның тормыш эшчәнлеге чикләнүен исәпкә алып урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен алу өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язу, билге һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны контрастлы яссылыкта башкарылган Брайльнең рельефлы-нокталы шрифтындагы тамгалар белән кабатлау;

ж) махсус укытылуын расылый торган, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386 номерлы "Йөртүче этне махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында" боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелгән документ булган очракта, объектка озата баручы этләр белән кертелүне тәэмин итү.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә инвалидларга дәүләт хезмәтләреннән файдалану өчен түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында үзләре өчен аңлаешлы формада мәгълүмат алу өчен кирәкле ярдәм күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ым-ишарә телен кулланып дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән объектка сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче кертүне тәэмин итү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтен алырга комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә башка төрле ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы документ, белдерү һәм күрсәтмәләрнең (шул исәптән мәгълүмати стендта) рельефлы-нокталы Брайль шрифтында һәм контрастлы фонда башкарылган күчермәләренең, шулай ук теркәү бүлегендә аудиоконтурының булуы.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә реконструкцияләнгән, яңартылган объектларга һәм чараларга карата кулланыла»;

2.14 бүлектәге «Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 14 ст., 15 ст.; Россия Хезмәт министрлыгының «Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә инвалидларның файдалана алуы һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалану шартларын тәэмин итү тәртибен раслау, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында» 2015 елның 30 июлендәге 527н номерлы боерыгы;

3 бүлектәге 3.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Бүлектә юлда йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматлар булмаганда, үзәк бүлеге белгече ведомствоара электрон багланышлар системасы аша белешмәләр бирү турында запросларны электрон формада җибәрә:

Россия Федерациясе Пенсия фондына: барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан иминиятләштерелгән затның социаль түләүләр күләме турында;

Россия Федерациясе Пенсия фондына: эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан физик зат файдасына исәпләнгән түләүләр һәм башка күчерүләр суммасы турында;

Россия Федерациясе Пенсия фондына шәхси исәп-хисап счетының иминият саны турында

Россия Эчке эшләр министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында, Россия Эчке эшләр министрлыгына;

Россия Оборона министрлыгы тарафыннан түләнә торган пенсия күләме турында, Россия Оборона министрлыгына;

медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча, һөнәри эшкә яраклылык югалган булса, медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча, иминиятләштерелгән затның үлеме иминият очрагы килеп

туган очракта, житештерүдәге бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча айлык иминият түләүләре турында, Россия Федерациясе Социаль иминият фондына;

Россия Федерациясе Пенсия фондына: “Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында”, “Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында” һәм “Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында” Федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына гражданның 2018 елның 31 декабренә торышы буенча туры килүе турында белешмәләр;

вакытлыча эшкә яраксызлык буенча пособие турында Россия Федерациясе Социаль иминият фондына;

вәкаләтле органнарга: 2013 елның 23 октябренә кадәр туган балаларны дәүләт теркәве турында;

тәрбиягә алучы гаиләгә баланы тапшыру турында белешмәләрне җирле үзидарә органнарына;

җирле үзидарә органнарына: ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү турында;

җирле үзидарә органнарына: опека (попечительлек) билгеләү турында;

әгәр гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелгән булса, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына: мөрәҗәгать итүче паспортының дөреслеген раслау турында;

әгәр гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәрелгән булса, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына: гаризада күрсәтелгән яшәү урыны буенча алучының теркәлү дөреслеген раслау турында;

мөрәҗәгать итүченең кучемсез милеге булуы турында белешмәләрне Росреестрга;

билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак бина турында, җирле үзидарә органнарына;

мөрәҗәгать итүченең транспорт чараларының, үзйөрешле транспорт чараларының һәм башка төр техниканың булуы турында вәкаләтле органга;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булуы турында.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны кабул итү һәм теркәү кенендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында запрос.».